# Татарский

1 Иң башта Сүз булган, Сүз Аллаһы белән булган, һәм Сүз Аллаһы булган. 2 Сүз иң башта
ук Аллаһы белән булган. 3 Бар нәрсә Сүз аша яратылган, һәм яратылган һәр нәрсә Аннан
башка яратылмаган. 4 Аңарда тормыш булган, һәм шул тормыш кешеләргә яктылык биргән.
5 Яктылык караңгылыкта яктыра, караңгылык исә аны сүндерә алмаган.
6 Аллаһы тарафыннан җибәрелгән Яхъя исемле бер кеше бар иде. 7 Яхъя шаһитлек бирү
өчен килде. Ул, барысы да иман китерсеннәр дип, Яктылык хакында шаһитлек бирергә
килде. 8 Ул үзе Яктылык түгел, ләкин Яктылык хакында шаһитлек бирү өчен җибәрелгән
иде.
9 Дөньяга килүче һәр кешене яктыртучы Яктылык – чын Яктылык иде. 10 Ул дөньяда
булды, ләкин дөнья, Аның аша яратылган булуга карамастан, Аны танымады. 11 Ул Үз
кешеләре янына килде, әмма үзенекеләр Аны кабул итмәде. 12 Ә Аны кабул итеп, Аңа иман
китерүчеләргә Ул Аллаһы балалары булырга хокук бирде. 13 Алар каннан да, тән
нәфесеннән дә, ир нәфесеннән дә түгел, бәлки Аллаһыдан тудылар.
14 Сүз Кеше булды, мәрхәмәт һәм хакыйкать белән тулы булып, безнең арабызда яшәде, һәм
без Аның данын, Атаның бердәнбер Улына биргән данын күрдек.
15 Яхъя пәйгамбәр Аның хакында шаһитлек биреп:
– «Миннән соңрак Килүче миннән алга чыкты, чөнки Ул миннән элек бар иде» дип
сөйләгәнем менә Шул инде, – дип кычкырып әйтте.
16 Аның тулылыгыннан без һәммәбез мәрхәмәт өстенә мәрхәмәт алдык, 17 чөнки канун
Муса аркылы бирелгән, мәрхәмәт һәм хакыйкать исә Гайсә Мәсих аша килде.